Тукай муниципаль районы Сәмәкәй авыл җирлеге Сәмәкәй авылы

**ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ**

«31» октябрь, 2020 ел № 2

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законынын 35 статьясы нигезендә Сәмәкәй авылы гражданнар җыены

**КАРАР БИРДЕ:**

1. ««2021 елда яшәү урыны буенча Сәмәкәй авыл җирлеге Сәмәкәй авылы территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешегә 500 (биш йөз) сум күләмендә бер тапкыр түләү кертергә һәм I, II төркем инвалидлары һәм Бөек Ватан сугышы ветераннары, ялгыз яшәүче өлкән яшьтәге гражданнар һәм көндезге формада укучы студентлар, күп балалы гаиләләр өчен бер тапкыр түләү күләмен киметергә һәм аны әлеге категория гражданнар өчен 250 (ике йөз илле) сум күләмендә билгеләргә, әлеге сумманы түбәндәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерергә:

1) Айдар Биктимеров урамы буенча юл ремонтлау;

2) Үзәк һәм Елга урамы арасындагы тыкрык буенча юл ремонтлау;

2. Тукай муниципаль районы Сәмәкәй авыл җирлеге Сәмәкәй авылы гражданнар җыены нәтиҗәсен авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштырып, халыкка житкерергә.

3. Тукай муниципаль районы Сәмәкәй авыл җирлеге Сәмәкәй авылы гражданнар җыены нәтиҗәсен Тукай муниципаль районының рәсми сайтында «авыл җирлекләре» бүлегендә, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында урнаштырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Сәмәкәй авыл җирлеге Башлыгы И.М.Усманов